ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11 статья. **Дәүләт хезмәтенең классы чиннары**

1. Дәүләт хезмәткәрләренә дәүләт хезмәтенең классы чиннары (алга таба шулай ук – классы чиннар) классы чиннарның дәүләт хезмәте вазыйфаларына әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә туры килүенә таянып бирелә.

2. Әлеге Законга 1 нче кушымтада күрсәтелгән дәүләт хезмәте вазыйфалары Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры нигезендә билгеләнә.

3. Классы чин беренче яисә чираттагы булырга мөмкин.

4. Беренче классы чин классы чины булмаган һәм классы чиннар бирелә торган дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүче дәүләт хезмәткәренә бирелә. Классы чин бирелгәндә әлеге Законның $11^3$ статьясы нигезендә федераль дәүләт граждан хезмәте классы чины, дипломатик ранг, хәрби яисә махсус исем, Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт граждан хезмәтенең классы чины яисә

муниципаль хезмәтнең классны чины исәпкә алына.

5. Беренче классны чин булып (дәүләт хезмәтенең дәүләт хезмәткәре били торган дәүләт хезмәте вазыйфасы карый торган вазыйфалары төркеменә бәйле рәвештә) түбәндәгеләр санала:

1) кече төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары өчен – 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре;

2) өлкән төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары өчен – 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты;

3) әйдәүче төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары өчен – 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе;

4) баш төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары өчен – 3 классны Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе;

5) иң югары төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары өчен – 3 классны Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе.»;

2) $11^3$ статьяда:

а) 1 өлештә «беренче» сүзен төшереп калдырырга;

б) 6 өлештә «Чираттагы» сүзен төшереп калдырырга;

3) 45 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктында «кушымта» сүзен «2 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле 1 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәте турында»
Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

| Классны чин | Дәүләт хезмәте вазыйфалары |
|---|---|
| 1 классны Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе | иң югары төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары |
| 2 классны Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе | |
| 3 классны Татарстан Республикасы хакыйкый дәүләт киңәшчесе | |
| 1 классны Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе | баш төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары |
| 2 классны Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе | |

| | |
|---|---|
| 3 классы Татарстан Республикасы дәүләт киңәшчесе | |
| 1 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе | |
| 2 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе | әйдәүче төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары |
| 3 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте киңәшчесе | |
| 1 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты | |
| 2 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты | өлкән төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары |
| 3 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте референты | |
| 1 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре | |
| 2 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре | кече төркем дәүләт хезмәте вазыйфалары |
| 3 классы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте секретаре | |

»;

5) кушымтаны 2 нче кушымта дип санарга.

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. 2020 елның 1 октябренә кадәр муниципаль хокукый актларда авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрендә һөнәри белем дәрәҗәсенә карата – урта һөнәри белем һәм муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш

стажына карата тиешенчә кимендә ике ел яисә кимендә өч ел стаж булу каралырга мөмкин. Күрсәтелгән вазыйфаны биләү өчен әлеге Кодексның 8 статьясындагы 3 өлешенең 1 пунктында каралган квалификация таләпләре 2020 елның 1 октябреннән соң вазыйфага 2020 елның 1 октябренә кадәр билгеләнгән һәм әлеге өлеш нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актларда каралган квалификация таләпләренә туры килә торган муниципаль хезмәткәрләргә карата кулланылмый.»;

2) 5 өлештә «2019 елның 1 гыйнварына» сүзләрен «2022 елның 1 гыйнварына» сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пунктының гамәлдә булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 27 декабрь
№ 118-ТРЗ